СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366)94-2-37, факс (84366)94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 158** **“21” август 2019 ел**

**Апаз авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 85 номерлы «Җир салымы турында " карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Уставы нигезендә Апаз авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Апаз авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 85 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,08 процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан гына үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003056